КАБИНЕТ МИНИСТРОВ РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ МИНИСТРЛАР КАБИНЕТЫ

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

2018 ел, 24 август г.Казань № 709

Татарстан Республикасы дәүләт хакимияте башкарма органнары максатлары һәм бурычларын гавәми формалаштыру буенча пилот проектын тормышка ашыру турында

Татарстан Республикасы дәүләт хакимияте башкарма органнары максатлары һәм бурычларын формалаштырганда җәмәгатьчелек фикерен исәпкә алуны тәэмин итү максатларында, «Дәүләт органнары һәм җирле үзидарә органнары эшчәнлеге турында мәгълүматны алу мөмкинлеген тәэмин итү турында» 2009 елның 9 февралендәге 8-ФЗ номерлы Федераль законның 6, 13 статьялары, «Россия Федерациясендә җәмәгатьчелек контроле нигезләре турында» 2014 елның 21 июлендәге 212-ФЗ номерлы Федераль законның 5, 24 статьялары нигезендә Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты КАРАР БИРӘ:

1. 2018 – 2019 елларда 2019 елга Татарстан Республикасы дәүләт хакимияте башкарма органнары максатлары һәм бурычларын гавәми формалаштыру һәм аларның үтәлешенә җәмәгатьчелек контроле буенча пилот проектын (алга таба – пилот проекты) тормышка ашырырга.

2. Карарга теркәлгән Татарстан Республикасы дәүләт хакимияте башкарма органнары максатлары һәм бурычларын гавәми формалаштыруны һәм аларның үтәлешенә җәмәгатьчелек контролен үткәрү тәртибен (алга таба – Тәртип) расларга.

3. Түбәндәгеләрне билгеләргә:

«Татарстан Республикасы Мәгълүмат технологияләре үзәге» Татарстан Республикасы дәүләт унитар предприятиесен пилот проектын тормышка ашыру, шул исәптән электрон сораштыру оештыру буенча техник оператор итеп;

Татарстан Республикасы Сәламәтлек саклау министрлыгын, Татарстан Республикасы Мәдәният министрлыгын, Татарстан Республикасы Мәгариф һәм фән министрлыгын, Татарстан Республикасы Хезмәт, эш белән тәэмин итү һәм социаль

яклау министрлыгын пилот проектлары катнашучылары итеп (алга таба – пилот проектын тормышка ашыруда катнашучы Татарстан Республикасы дәүләт хакимияте башкарма органнары).

4. Пилот проектын тормышка ашыруда катнашучы Татарстан Республикасы дәүләт хакимияте башкарма органнарына 2018 елның 15 декабренә кадәр әлеге расланган Тәртип нигезендә 2019 елга аларның максатларын һәм бурычларын гавәми формалаштыру үткәрүне тәэмин итәргә.

5. Республика «Татмедиа» басма һәм массакүләм коммуникацияләр агентлыгына пилот проектын тормышка ашыруда катнашучы Татарстан Республикасы дәүләт хакимияте башкарма органнары белән үзара багланышларда массакүләм мәгълүмат чараларында Татарстан Республикасы дәүләт хакимияте башкарма органнары максатлары һәм бурычларын гавәми формалаштыруны һәм аларның үтәлешенә җәмәгатьчелек контролен үткәрү тәртибе турында мәгълүмати-аңлату эшен тәэмин итәргә.

6. Татарстан Республикасы Иҗтимагый палатасына 2018 елның 5 сентябренә кадәр Татарстан Республикасы дәүләт хакимияте башкарма органнары максатлары һәм бурычларын гавәми формалаштыруда катнашу өчен экспертлар сайлап алу тәртибен һәм критерийләрен эшләргә һәм расларга, шулай ук һәр министрлык өчен экспертлар төркемнәре составын формалаштырырга тәкъдим итәргә.

7. Әлеге карарның үтәлешен тикшерүдә тотуны Татарстан Республикасында социаль активлыкның интеграцияләнгән платформасын һәм интерактив сервисларны үстерү буенча ведомствоара проект төркеменә йөкләргә.

Татарстан Республикасы
Премьер-министры
вазыйфаларын башкаручы Р.К.Нигъмәтуллин